

**Илһам бирче, каурый каләм!**

# Яшь каләмче

АПРЕЛЬ

2024ел

Яр Чаллы шәһәре 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе МАОУ “СОШ №40

## Апрель – Тукай ае, шигърият ае

### Газетабызның бу саны сөекле шагыйребез Габдулла Тукайга багышлана

*Апрель җитсә исемеңне*
*Җырына куша тургай.*
*Милләтемнең кояшы син*
*И моңлы ,нурлы Тукай!*




*26 апрель – халык шагыйре, милләтебезнең йөз аклыгы булган бөек шәхесебез – Габдулла Тукай туган көн. Бу датаны Татарстан һәм дөньяның төрле кыйтгаларына сибелеп яшәгән татар халкы Туган тел көне, Шигърият бәйрәме буларак зурлап билгеләп үтә.*

*Апрель ае – Тукай , шигърият, туган тел ае. Бөек шагыйребезнең гомере кыска булса да, ул бик күп әсәрләр иҗат итәргә өлгергән. Аның калдырган иҗат мирасы-безнең горурлыгыбыз.*

**Тукай премиясе лауреатлары билгеле**

Казан Кремлендә Татарстан Рәисе резиденциясенең Тантаналар залында Тукай премиясе лауреатлары игълан ителде.Быел Тукай премиясе шагыйрь Ләис Зөлкарнәйгә, сынчы Кадим Җәмитовка,ТР Дәүләт хоры җитәкчесе Миләүшә Тәминдаровага һәм язучы,тәрҗемәче Борис Вайнерга бирелде.



Тантана барышында шулай башка дәрәҗәле исемнәр дә тапшырылды. Тинчурин театры артисты Лилия Мәхмүтовага, җырчылар Эльмира Кәлимуллинага, Айгөл Бариевага, Вадим Захаровка һәм башкаларга Татарстанның халык артисты исеме бирелде. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов лауреатларны котлады.

Апрельне Тукай ае дип тә атыйлар, чөнки ул апрель аенда туган һәм шул ук айда вафат булган. Ул нибары 27 ел гына яшәп, бик зур иҗади мирас калдырган. Ул 10 меңнән артык шигырь юлы: 400 дән артык шигырь һәм 9 поэма, шулай ук 350 хикәя, очерк һәм истәлекләр иҗат иткән. Тукай хезмәтләре дөньяның 50дән артык теленә тәрҗемә ителгән. Бүген дә аның әсәрләре рус һәм башка милли телләрдә зур тираж белән нәшер ителә.

Республикабыз башкаласы Казанда, барлык шәһәр һәм районнарда, балалар бакчалары һәм мәктәпләрдә, шулай ук татарлар яшәгән чит илләрдә дә Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан тантаналы чаралар узды.

## Татар җәмәгатьчелеге Казанда Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салды








Чаллыда Габдулла Тукайның туган көненә багышланган бәйрәм чарасы шагыйрьнең *Тынычлык проспектында урнашкан* һәйкәле янында узды. Бирегә кечесеннән алып олысына кадәр милли җанлы, шигырь сөюче шәһәрлеләр җыелды.

Көндезге 12дән алып ике сәгать дәвамында һәйкәл каршында мәктәп укучылары өчен ирекле микрофон эшләде.«Быел да шәһәрнең 40тан артык мәктәбеннән йөзгә якын шигырь укучы катнашты», - диләр бәйрәмне оештыручылар.

Балалар чыгышыннан соң әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә нәтиҗәле хезмәт куеп, Габдулла Тукай исемендәге шәһәркүләм мактаулы бүләккә лаек булучыларга дипломнар һәм мэр бүләкләре тапшырдылар.

## Бәйрәм мизгелләре







Безнең мәктәп укучылары һәм укытучылары да шигърият бәйрәмендә катнаштылар. Тукай һәйкәленә чәчәкләр салдылар








**Тукай экиятләре**.
Су анасын укыгач, Тукаемның,
Күл буйларын кат-кат урадым,
Озын чәчле сихри су кызының
Күрмәмме дип алтын тарагын.
Балачакта урманнарга керсәм,
Һәр куакка текәлеп карадым.
Көтеп, бүрәнәгә кулын кыскан
Шүрәленең ярдәм соравын.
“Шагыйрәнә ялган” булсалар да,
Су анасы, дию, албасты.
Тукаемның шигъри экиятләре
Тылсымлы дөньяга юл ачты.
Шул дөньяга кереп балачакта
Сихри сукмаклардан атладым.
Сәмруг кошның каурыена тисәм,
Кулым пешәр, диеп уйладым.
Ул дөньяда тик яхшылык - патша.
Көчсез анда явызлык, ялган.
Кыюлыкка, дөреслеккә юлым
Тукай экиятеннән башланган.
Эчкерсезлек, гадилеге белән
Сабый күңеленә юл алган,
Тапкыр телле, сихри, могҗизалы
Тукай экиятләрен яратам.
Фәүзия Фәррахова

Тукай! Бу сүзне ишетү белән күңелдә ниндидер илаһилык, аңлатмаслык илһам, рухи нур барлыкка килә. Тукай иҗаты Җиһанга ямь, яктылык чыганагы, яшәү көче бөркеп, җирне, күңелләрне җылытып торучы мәңгелек кояш кебек үзенә бер илаһи көчкә ия.



Телсез идек – Тукай безне телле итте.
Җырсыз идек – Тукай безне җырлы итте.”

# Бәйрәм мизгелләре

Сөекле шагыйребезне безнең мәктәп укучылары да хөрмәтләп искә алдылар. Габдулла Тукайга багышлап,бик матур әдәби-музыкаль кичә булып узды.

Тукаебызның авыр тормыш сукмагын янә искә алып, аның берсеннән-берсе матур, безгә таныш булган шигырьләрен тыңлап киттек. "Кызыклы шәкерт", "Туган авылым", "Карлыгач", "Бала белән күбәләк" кебек әсәрләрен балалар бик матур итеп сөйләделәр, җырладылар, сәхнәләштерделәр. Тукай шигырьләренең туган телебездә генә түгел, ә рус телендә дә искиткеч матур яңгыравына тагын бер кат инандык.

Бәйрәм азагында барыбыз бергә "Туган тел" җырын җырладык. Бәйрәмдә катнашкан барлык балалар мактау кәгазьләре белән бүләкләнделәр.













# Шәп хәбәрләр!

## Айсылу-безнең мәктәп йолдызы





## Котлыйбыз!

Апрель ае башында "Безнең мәктәп йолдызы" исемле шәһәркүләм бәйгесенең финалы узды. Әлеге бәйгене “Көмеш кыңгырау" һәм "Мәйдан" журналы мәгариф идарәсе белән берлектә үткәрделәр.

Безнең мәктәп данын 2 нче "Д"сыйныф укучысы Айсылу Гыйззәтуллина яклады. Ул Булат Ибраһимовның "Бәхет алып булмый базар киштәсеннән" шигырен сөйләп, "Мәдәни юнәлеш" номинациясендә беренче урынны яулады. Айсылу - үзе матур, үзе сылу, үзе оста итеп шигырь сөйли, үзе җырлый. Бар яктан да килгән-булган кыз! Шәһәркүләм бәйгедә җиңүе белән котлыйбыз һәм яңадан-яңа уңышларга ирешүен телибез !

“Тукай- илһам чыганагы” исемле шәһәркүләм бәйгесендә катнашып, 2 нче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнгән Давлетшина Илинаны һәм аның укытучысы Чулпания Рәсуловнаны уңышлары белән котлыйбыз.
Киләчәктә дә уңышлар телибез!


Муниципальное бюджетное учреждение
«Централизованная библиотечная система»
ДИПЛОМ
II место
в городском творческом конкурсе
«Тукай – источник вдохновения»
награждается
Давлетшина Илина
МАОУ «СОШ №40 с уиоп»
Руководитель: Смирнова Ч. Р.
Номинация: «Презентация»
Возрастная категория: 10 – 14 лет
Директор В.М. Гайнуллина
г. Набережные Челны
2024 г.

## Әфәрин, кызлар!



Сынамышлар

* Апрель артык җылы булса, май салкын, җилле булыр.
* Апрельнең  алтысында торна кычкырса, ел яхшы килә.
* Апрель яңгырлы булса, гөмбә  уңар.
* Ай башында яшен яшьнәсә, җәй җылы килер һәм чикләвек мулдан булыр.
* Апрельдә көндез – кызу, төнлә салкынча булса, җылы җәй юрыйлар.
Ай ахырында төннәр йолдызлы  булса, уңыш уңар. Соңгы ун көнендә яңгырлар яуса да ел уңдырышлы булыр.
* Апрельдә каен суы күп акса, җәй яңгырлы килер.
* Апрельдә карлыгачлар килмәү – салкын язга.



## Апрель ул нинди була?!

Апрельме, апрель ул –
Яз көч туплаган вакыт.
Табигатьнең яшәрүен
Күкләр хуплаган вакыт.

Апрельме, апрель ул –
Аю уянган вакыт.
Җылы яктан кошлар кайтып,
Сайрап, куанган вакыт.

Апрельме, апрель ул –
Умырзаялы мизгел!
Мәхәббәт көткән күңелләр
Апрельдә була сизгер...

Апрельме, апрель ул –
Ләйсән яңгырлы көннәр!
Апрельдә чагын дөньяның
Яратмас инде кемнәр?..

Ләйсән Якупова.





**Газетаның баш мөхәррире  Таҗиева Р.Р.**